ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

24 октябрь, 2017 ел № 20/9

Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге 27/14 санлы «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезнамәне раслау хакында» Карарын гамәлдән чыккан дип тану турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт күзәтчелеген (надзорын) һәм муниципаль күзәтчелекне гамәлгә ашыру барышында юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 294-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2011 елның 10 октябрендәге «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 72-ЗРТ санлы Законы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Гамәлдән чыккан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезнамәне раслау хакында 27/14 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2013 ел, 20 ноябрендәге 87 нче санында бастырылган;

2) Шәһәр Советының 2014 елның 17 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезнамәне раслау хакында 27/14 санлы Карарына үзгәрешләр кертү турында» 30/10 санлы Карарын,

«Челнинские известия» газетасының 2014 ел, 23 апрелендәге 30 нчы санында бастырылган;

3) Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезнамәне раслау хакында 27/14 санлы Карарына үзгәрешләр кертү турында» 39/16 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2015 ел, 13 маендагы 34 нче санында бастырылган.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев